**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «27» декабреннән №51-393

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль-шәхси партнерлык турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 26 маендагы 34-270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында дәүләт-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 26 маендагы 34-270 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль-шәхси партнерлык турындагы Нигезләмәгә алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 7 бүлекнең 7.2 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 7.2 .1 өлешен өстәргә:

«7.2.1. Әлеге бүлекнең 7.1 өлешендә күрсәтелгән объектка карата килешү төзү вакытына мондый объект Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объекты (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) яисә ачыкланган мәдәни мирас объекты булса, төзелү рөхсәт ителми.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов